ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** **18.03.2024** **Чистай шәһәре** ***Карар*** **№ 94**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «Спорт судьясының квалификация категориясен бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 28 июнендәге 366 номерлы карары белән расланган спорт судьясының квалификация категориясен бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Прокурорның өлкән ярдәмчесе Салихов Р.Р. катнашында Чистай шәһәр прокуратурасының 2024 елның 6 мартындагы 02-08-02-2024 протестын карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законы, «Спорт судьялары турындагы нигезләмәне раслау турында» Россия Спорт министрлыгының 2017 елның 28 февралендәге 134 номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «Спорт судьясының квалификация категориясен бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 28 июнендәге 366 номерлы карары белән расланган спорт судьясының квалификация категориясен бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «1.2. Хезмәтне алучылар: исемлеккә кертелгән региональ спорт федерацияләре, физкультура-спорт оешмалары, федераль орган бүлекчәсе яисә вазыйфаи зат»;

1.2.

1.3. 2.4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.1. Квалификация категориясен бирү өчен документлар теркәлгән көннән алып 16 эш көнен тәшкил итә.

Квалификация категориясен бирү турында яисә бирүдән баш тарту турында карар квалификация категориясен бирү өчен документларны карау йомгаклары буенча 3 эш көне эчендә кабул ителә. Квалификация категориясен бирү турындагы карар җирле үзидарә органының оештыру-боеру акты белән рәсмиләштерелә.»;

1.4. 2.5.1 пунктның 8 абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

1.5. 2.5.1 пунктының 9 абзацында «чакырылыш» сүзләреннән соң түбәндәге сүзләрне өстәргә: «(Россия Федерациясе гражданы паспорты булмаган очракта)»;

1.6. 2.5.1 пунктта «документларның гамәлдә булу срогы» сүзләреннән соң түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«в) чит ил гражданы паспортының йә 115-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән яисә Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе нигезендә чит ил гражданының шәхесен таныклаучы документ буларак танылa торган башка документның күчермәсе - чит ил гражданнары өчен;

г) чит дәүләт тарафыннан бирелгән һәм Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә гражданлыгы булмаган затның шәхесен таныклаучы документ буларак танылa торган документның күчермәсе яисә 115-ФЗ номерлы Федераль законда каралган яисә Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә гражданлыгы булмаган затның шәхесен таныклаучы документ буларак танылa торган башка документның күчермәсе - гражданлыгы булмаган затлар өчен.»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (http://chistopol.tatar.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов